**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 13.01.2020** **№ 10**

**«2019-2024 нче елларда Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

2007 нче елның 24 нче июленнән 209-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турындагы" Федераль законны, 2010 нчы елның 21 нче январеннән 7-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турындагы" Татарстан Республикасы законын үтәү, инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм тотрыклы эш алып баруга шартлар тудыру һәм Биектау муниципаль районының социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен чишүдә аның өлешен арттыру максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә, "2019-2024 чне елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү" муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Биектау муиципаль районы Башкарма комитетының "2019-2023 нче елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү" муниципаль программасын раслау турындагы" 2019 нчы елның 5 нче апреленнән 735 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге Программаның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
ТР Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 13.01.2020
номерлы 10
Карары белән расланган

**Муниципаль программа**

«2019-2024 нче елларга Биектау муниципаль районында
кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү»

2019 нчы ел

**1. Муниципальной программаның паспорты**
«2019 – 2024 нче елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү»

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2019 – 2024 нче елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» (ары таба - Программа) |
| Программаны эшләүче | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсе икътисад бүлеге |
| Программаны төп башкаручылары | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсе, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| Программаның максаты | Инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлекне (КУЭ) үстерү һәм тотрыклы эш алып баруга шартлар тудыру һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен чишүдә аның өлешен артты |
| Программаның бурычлары | 1) Инновацион эшмәкәрлеккә ярдәм итү механизмнарын эшләү һәм кертү;<br>2) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;<br>3) Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен инфраструктураны үстерү;<br>4) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен нәтиҗәле мәгълүмати системаларны формалаштыру;<br>5) Җитештерүне технологик яктан кабаттан коралландыруга булышлык күрсәтү;<br>6) Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешендә административ киртәләрне киметү;<br>7) Кадрлар потенциалын арттыру;<br>8) Эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, яшьләр арасында эшмәкәрлек үстерү;<br>9) Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларның (СОКБО) эшчәнлегенә ярдәм итү. |
| Программаның максатчан индикаторлары | тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өлеше, %;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, берәмлек;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль булучылар саны, кеше;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлектә әйләнеш, млрд. сум;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларда катнашу өлеше, %; |

| | |
|---|---|
| | - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегеннән берләштерелгән ТР бюджетына салым кертемнәре күләме. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2019–2024 нче еллар |
| Елларга бүлеп программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны тулаем финанслауның гомуми күләме 10000 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән республика бюджетыннан, район бюджетыннан* (өстәмә керемнәр булган очракта) һәм башка чыганаклар:<br>2019 - 1500 мең сум;<br>2020 - 2000 мең сум;<br>2021 - 2000 мең сум;<br>2022 - 2500 мең сум;<br>2023 - 2000 мең сум.<br>2024 - 1500 мең сум<br>* - финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Биектау муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен истә тотып ел саен тәгаенләнә. |
| Программаны үтәүне контрольдә тоту | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУсе |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | 2024 нче елга көтелгән нәтиҗәләр:<br>1) тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше арту 34,0 %ка кадәр;<br>2) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны арту 840 берәмлеккә кадәр (ШЭ – 1450 берәмлеккә кадәр);<br>3) кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль булучылар саны, шәхси эшмәкәрлекне дә кертеп 6740 кешегә кадәр арту;<br>4) кече һәм урта эшмәкәрлектә әйләнеш арту 20,6 млрд. сумга кадәр;<br>5) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларда катнашу өлеше 68%ка кадәр арту;<br>6) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегеннән берләштерелгән ТР бюджетына салым кертемнәре күләме 450 млн.сумга кадәр арту. |

## 2. Кереш

Программа “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2007 нче елның 24 нче июленнән 209-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 нчы елның 8 нче августыннан 78 номерлы карары белән расланган 2016-2021 нче елларга һәм 2030 нче елга кадәр планлы чорга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисади үсеш Стратегиясе нигезендә эшләнгән.

Әлеге Программа 2019-2024 нче елларга Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм муниципаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә сәясәтен билгели һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү юлы белән районның социаль-икътисади үсеше проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге заман шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең үзенә бер төрле ролен түбәндәге факторлар билгели:

- көндәшлек мохите, цивилизацияле базар мөнәсәбәтләрен формалаштыру;
- товарларның (эшләр, хезмәтләр) ассортиментын киңәйтү һәм сыйфатын арттыру;
- хезмәт базарында социаль киеренкелекне киметү;
- халыкның гомуми керемнәр күләмен арттыру;
- барлык дәрәҗә бюджетларны формалаштыруда эшмәкәрлек эшчәнлеге тәэсире;
- эшмәкәрлек эшчәнлеге турында уңай иҗтимагый фикер формалаштыру.

Программа чараларын тормышка ашыру, шулай ук оешмаларның кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү район инфраструктурасын барлыкка китерүче көчләрне берләштерергә, эшмәкәрлек үсешенә комачаулаучы факторларны юкка чыгарырга һәм Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан бизнеска ярдәм итүне шактый үстерергә мөмкинлек тудырачак.

## 3. Программаның гомуми өлеше

### 3.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты булып инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм тотрыклы эш алып баруга шартлар тудыру һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен чишүдә аның өлешен арттыру тора.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны чишү кирәк:


- инновацион эшмәкәрлеккә ярдәм итү механизмнарын эшләү һәм кертү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү өчен инфраструктураның үсеше;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен нәтиҗәле мәгълүмати системаларны формалаштыру;
- җитештерүне технологик яктан кабаттан коралландыруга булышлык күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек үсешендә административ киртәләрне киметү;
- кадрлар потенциалын арттыру;
- эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, яшьләр арасында эшмәкәрлек үсеше;
- социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларның эшчәнлегенә ярдәм итү.

### 3.2. Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенең хәзерге халәтенә анализ

Хәзерге заман шартларында икътисадны реформалауда һәм цивилизацияле базар мөнәсәбәтләре формалашуда, эчке һәм халыкара базарларда көндәшлекнең үсүендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү аеруча мөһим роль ала. Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк, үсеш алган илләрдә нәкъ менә урта классның тотрыклы финанс торышы төбәкнең барлык халкының чәчәк атуына дәлил булып тора. Бүгенге көндә Биектау муниципаль районында да кече һәм урта эшмәкәрлекнең ролен арттыруга ставка куелган.

Кече эшмәкәрлек Биектау муниципаль районы икътисадында, салым салына торган базаны формалаштыруда, халыкның ихтыяҗларын тәэмин итүдә, районның авыл хуҗалыгы һәм сәнәгый үсешендә аеруча әһәмиятле роль уйный. Нәкъ менә кече бизнес бик күпләргә бу тормышта үз урыннарын табарга, эшлекле һәм иҗади сыйфатларын ачарга, гаиләне тәэмин итәргә ярдәм итә.


Кече бизнес үсешен характерлаучы күрсәткечләрнең берсе булып, кече бизнесның саны һәм структурасы тора.




**3.2.1 нче рәсем – Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының гомуми саны, берәмлек**


2018 елда Биектау муниципаль районында 774 кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үз эшчәнлекләрен тормышка ашырды, бу 2017 елдагыдан 12%ка күбрәк. Болардан 765 субъект кече һәм микропредприятиеләргә, 9ы – урта предприятиеләргә карый.

Теркәлгән шәхси эшмәкәрләр саны да арта. 2017 ел дәрәҗәсенә теркәлгән шәхси эшмәкәрләр саны 14%ны тәшкил итте.





**3.2.2 нче рәсем – Теркәлгән шәхси эшмәкәрләр саны**

Районның кече һәм урта предприятиеләрендә мәшгуль булганнарның уртача исемлек саны 2018 елда 1%ка артты һәм 3981 кешене тәшкил итте.





**3.2.3 нче рәсем – Кече һәм урта предприятиеләрдә мәшгуль булганнарның уртача исемлек саны, кеше**

Кече һәм микропредприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы 2018 елның 3 нче кварталы нәтиҗәләре буенча 19237,6 сумны тәшкил итте, узган елның шул ук чорына карарта үсеш темплары 103%ны тәшкил итте.




**3.2.4 нче рәсем – Кече һәм микропредприятиеләрдә уртача айлык хезмәт хакы, сум**

2018 елда кече һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше 15,8 млрд.сумны, 2017 ел дәрәҗәсенә үсеш 108%ны тәшкил итте.




**3.2.5 нче рәсем – Кече һәм урта предприятиеләр әйләнеше, млрд.сум**

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының киләчәктә комплекслы үсеше максатларында хакимиятнең дәүләт һәм җирле органнарының ярдәме кирәк.

Эшмәкәрлекнең үсешен тотып торучы төп мәсьәләләр булып торалар: югары квалификацияле кадрлар кытлыгы; кече һәм урта бизнеска югары дәрәҗәдә салым йөкләнеше; финанс, җир, энергетика ресурсларын ала алуга аз мөмкинлекләр булу; административ каршылыклар булу; яңа җиһазлар алу белән проблемалар булу; кече һәм урта эшмәкәрлек житәкчеләренең һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукый, финанс, салым законнарын белүдә, электрон мәйданнарда сатуларда катнашуда белемнәренең аз дәрәҗәдә булуы.

Ахыргы 5 ел эчендә КУЭ өлкәсендә хәлләргә анализ уздырганнан соң, илдә икътисади хәлләрнең үсеш тенденциясе, якындагы биш елда КУЭкә ярдәм итү буенча

тырышлыкны беренче чиратта түбәндәгеләргә юнәлтергә кирәк:

- КУЭ өлкәсендә эшмәкәрләрнең эшлекле активлыгын һәм көндәшлекнең үсешен арттыру;
- предприятиеләр арасында, шулай ук КУЭ ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары арасында да регионара элемтәләр һәм халыкара хезмәттәшлекне үстерү, бу үз чиратында технологияләр һәм бизнес-модельләр трансфертына булышлык итәчәк;
- эшмәкәрлек эшчәнлегенә кагыла торган муниципаль хокукый актларны формалаштыруда эшмәкәрләрне катнаштыру механизмының нәтиҗәле эшчәнлеген оештыру, муниципалитетның эшмәкәрләр җәмгыяте белән “кире элемтә” механизмнарын алга таба үстерү;
- район өчен аеруча социаль-икътисади нәтиҗә бирүче КУЭнең өстенлекле төрләрен үстерү;
- финанс чараларын ала алуны үстерү, чөнки кече предприятиеләр өчен нәкъ менә финанс ярдәм итү ярдәм итүнең аеруча өстенлекле формаларының берсе булып тора;
- кече предприятиеләрнең “ныклык запасын” элемтәләр булдыру һәм эре җитештерү бизнесы белән кушылу юлы белән (җитештерү мәйданнары тәкъдим итү, аерым җитештерү операцияләре (төрү, территорияне җыештыру һ.б.) башкару) формалаштыру;
- эшче белгечлекләргә аеруча сорау булган квалификацияле кадрлар әзерләү мәсьәләсендә кече бизнес һәм уку йортлары вәкилләре белән хезмәттәшлекне тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- инновацияле югары технологияле бизнесны активлаштыру;
- эшмәкәрләр өчен норматив актларның көйләүче тәэсирен бәяләү практикасын куллануны активлаштыру.

### 3.3. Развитие МСП в различных выбранных секторах экономики.

Хәзерге вакытта кече предприятиеләр Биектау муниципаль районының барлык икътисад өлкәләрендә эшчәнлекләрен тормышка ашыралар. Ел саен районның социаль-икътисади үсешендә кече бизнесның өлеше тагын да саллы була бара. Кече эшмәкәрлек яңа предприятиеләр һәм эш урыннары барлыкка китерү юлы белән, халыкның мәшгульлеге, базарны төрледән-төрле товарлар һәм хезмәтләр белән тулыландыру проблемаларын хәл итүне тәэмин итә.

Кече һәм урта эшмәкәрлекнең гомуми структурасында иң күп чагыштырма авырлык күпләп һәм ваклап сатуга (37%) һәм эшкәртү җитештерүенә (15%) туры килә. Алга таба төзелеш өлкәсен оештыру (11%), транспорт һәм элемтә (8%), авыл хуҗалыгы (5%), күчемсез милек белән эш (7%), кунакханәләр һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре эшчәнлеге (2,5%), һәм башкалар.

Биектау районы төбәк дәрәҗәсендә эчке туризм үсеше өчен аеруча зур потенциалга ия.

Район территориясендә туризмның перспективалы төрләре булып торалар: рекреацион-сәламәтләндерү, спорт, тарихи-туган якны өйрәнү, агротуризм.

Бүгенге көндә районда, 2010 елда фермер Г.Котдусов үз хуҗалыгы базасында оештырган “Татар страусы” туристик комплексында экотуризм актив үсеш ала.

**2018 елның 1 нче июленә эшчәнлек төрләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, берәмлек**




Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк, ахыргы биш елда кече һәм урта предприятиеләренең җитештерү өлкәсендә уңай үсеш тенденцияләре барлыкка килде. Аларның КУЭ структурасында өлеше 2013 елда 10,0%тан 2018 елга 15%ка кадәр артты. Эшкәртү җитештерүендә «Синтез-Сандра» ҖЧҖ, «СХП "Барс-Агро» ҖЧҖ, «Элит Мастер Кофе» ҖЧҖ, «Касымовский» сөт комбинаты ҖЧҖ кебек предприятиеләр уңышлы үсеш алалар.

Эшкәртү өлкәсе белән беррәттән төзелеш өлкәсе дә югары әйләнеш темпларын күрсәтә (үсеш 2 тапкырга күбрәк). Әлеге өлкәнең аеруча да уңышлы вәкилләре булып «Финдом» ТК ҖЧҖ, «Глафстрой» ҖЧҖ, «Барсэлитстрой» ҖЧҖ, «Многоотраслевое Предприятие-Мп» санала.

### 3.4. Кулланучылар базары һәм кооперация элемтәләре үсеше

Биектау районы икътисадының һәм кече һәм урта эшмәкәрлекнең мөһим өлкәсе булып эш урыннары булдыруда зур роль уйнаучы (КУЭтә мәшгуль булганнарны 30%тан артыгы), кече һәм урта эшмәкәрлекнең барлык предприятиеләре

әйләнешенең яртысыннан артыгын формалаштыра торган (55%) кулланучылар базары тора.

Хәзерге вакытта Биектау районында 250 дән артык стационар ваклап сату, шул исәптән ваклап сату челтәрләре һәм 23 җәмәгать туклану предприятиеләре бар. Кече форматтагы сату итү дә саклана һәм үсеш ала.

2018 елның 9 аена ваклап сату әйләнешенең үсеше 3,0 млрд.сумга кадәр арту (үсеш темпларын узган елның шул ук чорындагы бәяләр белән чагыштырганда 109,0%) шулай ук кулланучылар базарының үсешен дәлилли.

Ваклап сату объектларының саны арту кулланучылар базарында бәяләрнең бернинди сәбәпсез күтәрелүен тотып торучы, еш кына аларның кимүенә дә булышлык итүче көндәшлек мөнәсәбәтләре барлыкка килүенә китерә.

Ваклап сатуда өстәмә чыгымнарның чагыштырмача аз дәрәҗәсе, бәяләр дәрәҗәсен ваклап сатуның стационар челтәрләрендәге бәяләрдән түбәнрәк тотарга мөмкинлек бирә. Моның белән бәйле рәвештә ваклап сатуга аеруча да зур игътибар бирелә.

Халыкны җирле товар җитештерүчеләр җитештергән сыйфатлы товарлар белән тәэмин итү максатыннан, һәркем алырлык бәяләр буенча ярминкәләр оештырыла.

2019 елның 1 нче гыйнварына 8,4 млн сумга продукция сатылган 44 авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек ярминкәсе уздырылган.

### 3.5. Эшмәкәрлекне популярлаштыру һәм яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү

Яңа проектларны күрсәтү, хезмәттәшлекне үстерү һәм сату базарын киңәйтү өчен яхшы мәйдан булып районда уздырылучы зур чаралар тора. Әлеге чаралар безнең район предприятиеләренең продукцияләре күргәзмәләрен оештыру белән бергә уздырыла, бу исә кооперация элемтәләрен җайга салуга булышлык итә.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүматны җиткерү өчен районның рәсми сайтында махсус өстәмә бит булдырылган, аның аша алар финанс һәм милки ярдәм чаралары һәм төрләре турында актуаль мәгълүмат, мәгълүмати маркетинг, хокукый мәгълүмат ала алалар.

Моңа өстәп, 2018 елда министрлык һәм ведомстволардан кирәкле методик ярдәм күрсәтү өчен, шулай ук эшмәкәрләр белән үзара мөнәсәбәтләрнең “тере” мәйданын булдыру максатыннан, айның һәрбер беренче дүшәмбесендә бизнес вәкилләре белән очрашулар уздырылды. Әлеге очрашулар моннан соң да уздырылачак.

Эшмәкәрлекне популярлаштыру буенча чаралар гомуми белем бирү оешмаларында тормышка ашырылалар. Болар уен, тренинг, укыту чаралары, бәйгеләр, семинарлар, мастер-класслар һ.б.

Эшмәкәрлекне популярлаштыру һәм ярдәм итү максатыннан башкарма комитет ТР Икътисад министрлыгы белән бергә “Бизнес-Десант”, “Эшмәкәрлек Фабрикасы”, “Бизнескласс” белем бирү проектлары кысаларында эшләрен башлап килүче эшмәкәрләргә укыту оештырды. Барлык проектлар да Биектау муниципаль районы халкының актив өлешен эшмәкәрлек эшчәнлегенә тартуга юнәлдерелгән. 2018 елда “Бизнес-класс” программасы буенча 56 кеше

укыту узды. Программа эшли башлаганнан барлыгы 200дән артык кеше укыту узды.

Яшьләр эшмәкәрлеге потенциалын тормышка ашыру өчен өч өстенлеккә ияреп барырга кирәк: яшьләрне социаль практикага җәлеп итү һәм аларга үсеш мөмкинлекләре потенциалы турында мәгълүмат бирү; яшьләрнең барлыкка китерү активлыгын үстерү; авыр тормыш хәлендә калган яшь кешеләрне интеграцияләү.

Яшьләр эшмәкәрлеге үсешенә булышлык итүче чараларга түбәндәгеләрне кертергә кирәк:

- яшьләр эшмәкәрлеген оештыру өчен перспективалы эшмәкәрлек идеяләрен сайлап алу;
- яшь кешеләрдә бизнес алып бару сәләтләрен булдыру өчен профильле уку оештыру;
- коммерцияле булмаган оешмаларның һәм социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның грант активлыгын арттыру.

### 3.6. Халыкның үзмәшгульлеген үстерү механизмы

Эшмәкәрлекне популярлаштыру максатыннан 2019 елдан үзмәшгуль гражданнар өчен махсус ташламалы салым режимы кертелә.

Законның көче үз эшчәнлегеннән керем алган, ләкин ялланган хезмәткәрләре булмаган һәм үзләре дә андый кеше булмаган гражданнарга кагыла. Еллык керем 2,4 млн. сумнан артмаска тиеш.

Әгәр дә гражданин үз товарын яки хезмәтен физик затларга сатса салымның күләме керемнең 4%ы, әгәр дә юридик затларга сатса – 6% булачак. Бу вакытта үзмәшгуль кешеләр 13% күләмдәге НДФЛ түләүдән азат ителәләр һәм аларга мәҗбүри пенсия иминиятенә иминият кертемнәрен ирекле тәртиптә түләргә рөхсәт ителә, ләкин әлеге кертемнәрнең максималь күләме чикләнгән. Ставкалар 10 ел эчендә үзгәртелмәячәк һәм хисап бирү таләп ителми.

Үзмәшгуль гражданнарны “һөнәри керемгә салым” буенча ИФНСка яңа махсус салым режимына хисапка кую үзмәшгульләргә бирелгән хабәрнамә нигезендә тормышка ашырыла һәм ирекле булып санала.

Гражданнарга уңайлы булсын өчен махсус мобиль кушымта проекты булдырылган, бу үзмәшгуль кешеләргә теркәлү үзәкләренә килми генә салым хезмәтендә теркәлергә мөмкинлек бирәчәк. Кушымта аркылы салым хисабыннан башка гына да, нинди дә булса махсус белешмә һәм документларны бирми генә дә түләүләрне тормышка ашырырга була.

Рәсми рәвештә теркәлгән вакытта үзмәшгуль кеше ала торган өстенлекләр:

- бизнесны алып баруны яхшырту өчен мәгълүмати ачыклык;
- үзенең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклау өчен судка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булу;
- киләчәктәге пенсияне рәсмиләштерү өчен стажны кертү;
- дәүләтнең ярдәм программаларында катнашу алу һәм кредитлар алу мөмкинлеге.

### 3.7. Сәнәгать мәйданнары үсеше һәм резидентлар җәлеп итү

Район территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге 2 сәнәгать мәйданы эшләп килә. Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү Комиссиясе утырышының 2018 ел, 29 нчы октябрь, 3П/2018 номерлы Беркетмәсе нигезендә, «НПО «Агросервис» ҖЧҖенә (“Агросервис” сәнәгать мәйданы) 1 ел срокка сәнәгать мәйданы буларак аккредитацияләү турында карар кабул ителде. Моның өстенә, УК “Хэф” ҖЧҖнең гаризасын карау нәтиҗәләре буенча, УК “Хэф” ҖЧҖнә 1 ел срокка барлыкка китерелә (проектлана) торган сәнәгать мәйданы сыйфатында аккредитацияләү турында карар (Комиссия утырышының 2018 ел, 21 нче декабрь, 5П/2018 номерлы Беркетмәсе) кабул ителде.

“Агросервис” сәнәгать мәйданы территориясендә туклану продуктлары, ачыклап әйткәндә аксымлы-витаминлы-минераль эчемлекләр җитештерү өчен бөртекләрне биологик эшкәртү буенча машиналар комплексын серияле җитештерү буенча технологик линия булдыру буенча проектны тормышка ашыру планлаштырыла.

“ХЭФ” мәйданы территориясендә дүрт резидент үз эшчәнлеген алып бара: “Биектау МТСы” ҖЧҖ һәм “Айрон Групп” ҖЧҖ (металл эшләнмәләр җитештерү), “Биектау СХТсы” ҖЧҖ (машиналар һәм җиһазлар ремонтлау), “Технология” ҖЧҖ (майлау материаллары җитештерү, майлау материалларына присадкалар). Әлеге мәйдан резидентларының хезмәтләре республикада гына түгел, аның чикләрендә дә сорау белән кулланыла.

Район сәнәгать мәйданнарының өстенлекләренә төбәк һәм федераль әһәмияткә ия булган транспорт чишелешләреннән, шулай ук Казан шәһәреннән турыдан-туры якында отышлы урнашуын кертергә була. Шулай ук сәнәгать мәйданнарының чикләренә кадәр каты өслекле юл бар.

Территориаль урнашу хезмәт ресурсларын һәм чималны сәнәгать зоналарына җиңел китерергә мөмкинлек тудыра.


Шулай кече бизнесны ныгыту һәм инвесторларны җәлеп итү максатыннан, шул исәптән чиктәш төбәкләрдән дә, “М7-Биектау” индустриаль паркын булдыру буенча эшләр алып барыла. Җир кишәрлеге схемасы формалаштырылган, Биектау муниципаль районы Дачное авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертелгән. Документлар хәзерге вакытта Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарында килештерүдә.

## 4.Территориянең инвестицион җәлеп итүенә бәя, эшмәкәрлекне үстерүнең юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге

Район икътисадындагы үзгәрешләрне чагылдыра торган мөһим күрсәткечләрнең берсе булып, инвестицион процессны характерлаучы күрсәткечләр тора. Районның инвестицион җәлеп итүенең төп шартлары булып эшмәкәрләр өчен

уңай инвестицион климат булдыру тора.

Инвестицияләр җәлеп итү максатыннан район җитәкчелеге тарафыннан даими нигездә потенциал инвесторлар белән очрашулар оештырыла.




**4.1. рәсем. Төп капиталга инвестицияләр, млн.сум.**

2011 елдан районда төп капиталга инвестицияләр буенча уңай динамика күзәтелә. 2018 елның 9 аенда район икътисадына 3,5 млрд.сум инвестицияләр җәлеп ителгән . Фаразларга караганда, 2018 ел нәтиҗәләре буенча инвестицияләр күләме 5 млрд.сумнан күбрәк булачак.

2018 елдагы төп инвестицияләү юнәлешләре – торак төзелеше, юл-транспорт инфраструктурасы.

Дәүләт ярдәме системасын камилләштерү һәм административ киртәләрне җиңеп чыгу кысаларында инвесторлар белән берлектә Биектау муниципаль районы Башлыгы “Инвестицион паспорт, инвестицион меморандум, инвестицион декларацияне раслау һәм Биектау муниципаль районы инвестицион (иҗтимагый) советын булдыру турында” 2014 ел, 13 нче август 85 номерлы карар расланды.

Инвесторларны җәлеп итү максатыннан Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан инглиз һәм кытай телләренә тәрҗемә белән районның инвестицион паспорты эшләнелде.

Инветицион эшчәнлек субъектлары белән хезмәттәшлек итүче Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары, билгеләнгән тәртиптә, Биектау муниципаль районы территориясендә инвестицион проектларны тормышка ашыруга каршылык тудыра торган административ каршылыкларны җиңеп чыгарга аларның тәкъдимнәрен карыйлар.

Биектау муниципаль районы территориясендә инвесторлар эшчәнлеген оештыру буенча инвесторларга муниципаль ярдәм чаралары күрсәтелә, шул исәптән:

- муниципаль базарның структурасы һәм күләме турында мәгълүмати тәэмин итү, инвестицион проектны тормышка ашыру өчен кирәкле хезмәт, җитештерү һәм инфраструктур ресурсларның концентрациясе;
- инвестицион проект (инвестицион мәйданнар) тормышка ашырыла

торган территория чикләрендә инфраструктура һәм кадрлар сәясәте буенча проектларны тормышка ашыруда булышлык;

- бизнес оештыру өчен буш торган мәйданнарны арендага тәкъдим итү.

## 5. КУЭ үстерү программаларын ресурслар белән тәэмин итү

Программаны ресурслар белән тәэмин итүне түбәндәге бюджет чыганаклары тәшкил итә:

1. Конкурс нигезендә Россия Федерациясе бюджетыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен (төгәл суммаларны күрсәтми генә фаразлана торган мөмкин булган чаралар чыганагы буларак) бүлеп бирелә торган чаралар.
2. Татарстан Республикасы бюджеты – Татарстан Республикасы бюджетында чираттагы финанс елына һәм планлы чорга күздә тотылган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтү чараларань тормышка ашыру өчен (төгәл суммаларны күрсәтми генә фаразлана торган мөмкин булган чаралар чыганагы буларак) тәгаенләнгән чаралар.
3. Биектау муниципаль районы бюджеты – ТР Биектау муниципаль районы бюджетыннан агымдагы һәм планлы чорга күздә тотылган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре хисабына) тәгаенләнгән чаралар.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм билгеле бюджетларның мөмкинлекләрен истә тотып ел саен тәгаенләнә.

## 6. Куркынычларны бәяләү, аларны киметү буенча чаралар

Бүгенге көндә кече һәм урта бизнес югары дәрәҗәдәге куркыныч, финанс резервларның түбән дәрәҗәсе, төп фондларның чикле булуы, кредитлар күп булуы һәм аның “икътисади тотрыксызлыгын” билгели торган башка күрсәткечләр белән характерлана.

Куркынычларны киметү буенча мәсьәләне чишү булып барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан финанслау булуы тора. Бу планлаштырылган чараларны үтәү өчен гарантия һәм муниципалитет тарафыннан эшмәкәрләр өчен хезмәтләр тәкъдим итү мөмкинлекләрен җәелдерү.

6.1. табл.

| Куркыныч төре | Тәэсир итү дәрәҗәсе | Килеп чыгу мөмкинлеге | Куркынычларны киметү буенча чаралар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| Эшмәкәрләрнең аерым ярдәм формаларына кызыксынуы кимү | Уртача | Уртача | Ярдәм итү чараларының кирәкле булуына даими рәвештә бәя бирү, муниципаль программа чараларының нәтиҗәлелеге анализ ясау |
| Федераль, төбәк һәм җирле дәрәҗәдә финанслау күләмнәре кимү | Югары | Уртача | Беренче чиратта финанслау өчен өстенлекләрне ачыклау. Бюджет кертемнәренең нәтиҗәлелегенә бәя бирү. |
| КУЭ субъектлары тарафыннан финанс ярдәме алган проектларны тормышка ашыруның тискәре нәтиҗәләре булу | Уртача | Түбән | Финанс ярдәм алуга һәм аларны тормышка ашыруның мониторингын тормышка ашыруга дәгъва иткән КУЭ субъектлары проектларына алдан экспертиза уздыру |
| Салым салу өлкәсендә шактый үзгәрешләр булу | Югары | Уртача | КУЭ субъектлары өчен салым |
| Куркыныч төре | Тәэсир итү дәрәҗәсе | Килеп чыгу мөмкинлеге | Куркынычларны киметү буенча чаралар |
| (КУЭ субъектларына салым салу нормалары һәм кагыйдәләре үзгәрүе, салымнарны артуы) | | | салу дәрәҗәсендәге үзгәрешләрнең нәтиҗәләре анализы. Салым салу ставкаларын нигезләү. Эшмәкәрләрнең иҗтимагый һәм һөнәри оешмалары һәм берләшмәләре белән үзара мөнәсәбәт. |
| Кече предприятиеләр өчен башка территорияләрдән эре уенчыларның килеп чыгу куркынычы туу | Уртача | Югары | Җирле эшмәкәрләрнең көндәшлеккә сәләтлелеген арттыруга гамәлләр кылу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары үзгәрү белән бәйле хокукый, норматив-хокукый базаны формалаштыру белән бәйле куркынычлар | Уртача | Уртача | Программа проектының килештерү этабында тәкъдимнәрне карау һәм әзерләү өчен районның предприятиеләрен һәм оешмаларын җәлеп итү күздә тотыла. |

## 7. Программаның планлаштырылган икътисади нәтиҗәлелеге, программа белән идарә итү һәм программаны тормышка ашыру буенча контроль

Программаның нәтиҗәлелегенә бәя бирү методикасы һәм критерийлары үз эченә  кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләренең анализын уздыруны, шулай ук Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген һәм аның районның социаль-икътисади халәтенә тәэсир итүен үз эченә ала.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча түбәндәге нәтиҗәләрне алу күз алдында тотыла:

- районның тулаем территориаль продуктында (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өлешен арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль булучы хезмәткәрләрнең санын арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларда катнашу өлешен арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлектә әйләнешен арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегеннән берләштерелгән бюджетка салым кертемнәре күләмен арттыру.

Программаны үтәү шулай ук ярдәм итәчәк:

- кече һәм урта эшмәкәрлекнең эшчәнлеген һәм тотрыклыгын булдыру өчен уңай икътисади  мохит формалаштыру;
- кече бизнеска салым һәм административ йөкләнешне оптимизацияләү, милек хокукларын саклау, эшмәкәрлек эшчәнлеген закон тарафыннан тану;
- кече һәм урта эшмәкәрлек секторына инвестицияләрне җәлеп итү һәм стимуллаштыру;
- кече эшмәкәрлек үсеше темпларын арттыру, кече предприятиеләрнең икътисади ныклыгын арттыру һәм эшчәнлек өлкәләрен киңәйтү;
- халыкның мәшгуль булуның өстәмә мөмкинлекләре булу, кече эшмәкәрлектә мәшгуль булган хезмәткәрләрнең хезмәт хаклары дәрәҗәсен арттыру;

- жирле житештерүнең көндәшлеккә сәләтле продукцияләре һәм хезмәтләре белән сату базарын тулыландыру;
- кече эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгын арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләрендәге хезмәт хакларын закон тарафыннан тану;
- хәйриячелек эшен үстерү.

Куелган максатларга ирешү һәм мәсьәләләрне чишү өчен чараларны биш ел дәвамында тормышка ашырырга кирәк. Программа чараларын тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре 8.1. таблицасында күрсәтелгән.

“2019-2024 елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программаны гомуми контрольдә тоту “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты” МКУ белән тормышка ашырыла.

## 8. 2019-2024 елларга Биектау муниципаль районында КУЭ үсеше буенча төп күрсәткечләр

8.1 таблица

| № т/б. | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тулаем территориаль продуктта (ТТП) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өлеше | % | 32,3 | 32,6 | 32,9 | 33,3 | 33,5 | 33,8 | 34,0 |
| 2 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (ШЭ) саны | берәмлек | 774 (1277) | 785 (1300) | 795 (1340) | 810 (1380) | 820 (1415) | 830 (1430) | 840 (1450) |
| 3 | Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгуль булучыларның саны (шул исәптән үзмәшгульлеләр) | сан | 5787 | 6 618 (768) | 6630 (768) | 6650 (768) | 6680 (768) | 6710 (768) | 6740 (768) |
| 4 | Кече һәм урта предприятиеләр әйләнеше | млрд. сум | 17,1 (бәя) | 17,8 | 18,5 | 19,2 | 19,7 | 20,2 | 20,6 |
| 5 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларда катнашу өлеше | % | 60,0 | 63,0 | 64,0 | 65,0 | 67,0 | 68,0 | 68,0 |
| 6 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегеннән берләштерелгән ТР бюджетына салым кертемнәре күләме | млн. сум | 9 айда 261 млн. сум | 360 | 370 | 390 | 410 | 430 | 450 |

**“2019-2024 нче елларга Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасының төп чаралары исемлеге**

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларны башкару сроклары | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **1 нче бурыч. Инновацион эшмәкәрлеккә ярдәм итү механизмнарын эшләү һәм кертү** | Үзмәшгуль гражданнарның бизнес планнарын субсидияләр бүлеп бирү максатыннан сайлап алу буенча халык мәшгульлеге үзәге комиссиясе составына банк оешмаларын кертү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| **2 нче бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын эшләү һәм тормышка ашыру** | КУЭ субъектларына идарә итүгә һәм (яки) файдалануга бирү өчен каралган муниципаль милекне түләүле яки ташламалы шартларда арендага һәм (яки) файдалануга бирү | «ТР Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Биектау муниципаль районында кече эшмәкәрлек үсешенә уңайлы шартлар тудыру максатыннан салым ставкаларын коррекцияләү турында тәкъдимнәр эшләү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Сәнәгать (индустриаль) парклар һәм сәнәгать мәйданнарын үстерү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Бюджеттан тыш чаралар |
| **3 нче бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен инфраструктураларны үстерү** | Муниципаль-шәхси партнёрлыкны үстерү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Бюджеттан тыш чаралар |

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларны башкару сроклары | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|
| **4 нче бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен мәгълүмати хезмәтләрнең эффектив системасын формалаштыру** | Кече эшмәкәрлек субъектлары, район җирле үзидарә органнары катнашында “түгәрәк өстәлләр”, семинарлар, конференцияләр уздыру; эшмәкәрлек эшчәнлеге мәсьәләләре буенча эшмәкәрләргә адреслы ярдәм күрсәтү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты |
| | Эшмәкәрлек инфраструктурасын хасил итә торган оешмалар белән очрашулар, утырышларүткәрү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Биектау муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәмярдәм итү өлкәсендә уздырыла торган чараларны мәгълүмати озата бару | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| **5 нче бурыч. Җитештерүне технологик яктан кабат кораллandыруга булышлык итү** | Эшмәкәрләргә финанс ярдәме чараларын сайлаганда булышлык күрсәтү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бакарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Эшмәкәрләргә республика һәм федераль ярдәм программалары буенча конкурсларда катнашуда булышлык күрсәтү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Җиһазларның лизинг үсеше: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының чыгымнарын субсидияләү (“Лизинг-грант”) | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Татарстан Республикасы бюджет |
| **6 нчы бурыч. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүдә административ киртәләрне киметү** | КУЭ кә ярдәм итү һәм үстерү мәсьәләләре буенча Координация Советы киңәшмәләрен уздыру | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Район эшмәкәрләренә “Тикшерелгән бизнес” проекты буенча мәгълүмат бирү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларны башкару сроклары | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|
| **7 нче бурыч. Кадрлар потенциалын үстерү** | “Эшмәкәрлек фабрикасы” проектын тормышка ашыруда булышлык итү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Тиз үсеш алучы җитештерүләргә хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә булышлык итү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| **8 нче бурыч. Эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыру, яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү** | Эшмәкәрлек буенча мәгълүмати буклетлар, материаллар булдыру | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Муниципаль берәмлек бюджет |
| | Массакүләм мәгълүмат чараларында үзмәшгуль гражданнарга салым салу турында законның үтәлеше буенча мәгълүматны яктырту | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Муниципаль берәмлек бюджет |
| | Массакүләм мәгълүмат чараларында үзмәшгуль гражданнарның уңышлы эш тәҗрибәсен яктырту | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Муниципаль берәмлек бюджет |
| | Тиз үсеш алучы җитештерүләр һәм инвестицияле урыннарны билгеләү буенча аналитик белешмәләр әзерләү | «Татарстан РеспубликасыБиектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Ел саен уздырыла торган “Яңа елга предприятиеләрне бизәү” конкурсын уздыру | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Муниципаль берәмлек бюджет |
| | Кече эшмәкәрлек субъектларын Татарстан Республикасында уздырыла торган күргәзмә, ярминкә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларны башкару сроклары | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|
| **9 нчы бурыч. Үз эшчәнлеген Биектау муниципаль районы территориясендә тормышка ашыра торган социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларның эшчәнлегенә ярдәм итү** | Биектау муниципаль районы территориясендә социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан халык чараларын уздыруга булышлык итү | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларның эшчәнлеген яктырту | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Муниципаль берәмлек бюджеты |
| | Социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмалар өчен консультацияләр (семинарлар) уздыру | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Финанслау таләп ителми |
| | СОКБО ларга субсидияләр бирү (СОКБО ларның фактик чыгымнарын кайтару) | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ | 2019-2024 нче еллар | Татарстан Республикасы бюджеты, муниципаль берәмлек бюджеты |